КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 14 ноябрь г.Казань № 946

Республика Татарстан Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1043 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 3 ноябрь, 1043 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 2 октябрь, 1205 нче, 2023 ел, 22 декабрь, 1667 нче, 2024 ел, 18 март, 152 нче, 2024 ел, 08 июль, 533 нче, 2024 ел, 7 август, 632 нче, 2024 ел, 23 декабрь, 1186 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 3 ноябрь, 1043 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 14 ноябрь, 946 нчы
карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы

«Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә стратегик приоритетлар

I. Сәнәгатенең эшкәртү тармаклары өлкәсендә хәзерге хәлне бәяләү

«Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт программасы) «Россия Федерациясендә сәнәгать сәясәте турында» 2014 елның 31 декабрендәге 488-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкурентлык сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 328 номерлы карары , Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 17 гыйнварындагы 20-б номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе электрон сәнәгатен үстерү стратегиясе (алга таба - Электрон сәнәгатьне үстерү стратегиясе), Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 6 июнендәге 1512-б номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр һәм 2035 елга кадәр чорга Россия Федерациясе эшкәртү сәнәгатен үстерүнең җыелма стратегиясе (алга таба - Эшкәртү сәнәгатен үстерү стратегиясе), 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм план, «2030 елга кадәр Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү стратегиясен раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба - Стратегия-2030) нигезендә эшләнде.

2022 елдан башлап Татарстан Республикасы сәнәгатен үстерүгә тышкы сәяси вәзгыять зур йогынты ясый. Иң мөһим сынау булып санкция басымы, глобаль кооперация һәм сәүдә бәйләнешләренең бозылуы, эшчәнлек активлыгының кимүе, нефть бәяләренең һәм валюта курсының үзгәрүчәнлеге тора.

Татарстан Республикасы төп макроикътисадый күрсәткечләр буенча Россия Федерациясе төбәкләре арасында алдынгы урыннарны саклый.

Тулаем төбәк продукты күләме буенча Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектлары арасында 7нче урында, сәнәгать җитештерүе күләме буенча – 5нче урында, авыл хуҗалыгы буенча – 5нче урында, төзелеш буенча – 2нче урында, сәүдә буенча – 7нче урында, инвестицияләр күләме буенча – 6нчы урында.

2025 елның гыйнвар – август айлары нәтиҗәләре буенча тулаем төбәк продукты, бәяләү буенча, 3 705,2 млрд.сум тәшкил иткән, яки 2024 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 102,9 процент. Икътисад структурасында иң зур өлешне традицион рәвештә сәнәгать алып тора. Сәнәгать җитештерү индексы 2024 елның шул ук чоры белән чагыштырганда 111,0 процент тәшкил иткән, төяп җибәрелгән продукция күләме – 3 743,0 млрд.сум. Файдалы казылмалар чыгару тармагында җитештерү индексы 2024 елның гыйнвар – август айларына карата 97,4 процент тәшкил иткән, эшкәртү производстволарында – 119,7 процент, электр энергиясе, газ, пар белән тәэмин итү, һаваны кондицияләү – 96,0 процент, су белән тәэмин итү, су агызу, калдыкларны җыю һәм утильләштерүне оештыру, пычрануларны бетерү эшчәнлеге – 97,6 процент.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы сәнәгатендәге хәл берничә проблеманың булуы белән характерлана. Алар арасында төп җитештерү фондларының югары дәрәҗәдә тузуы, предприятиеләрнең үз финанс ресурсларының җитмәве һәм яңа производстволарны оештыру һәм булганнарын модернизацияләү проектларын гамәлгә ашыру өчен заем акчаларының югары бәясе, эчке базарда түләүгә сәләтле ихтыяҗның чикләнгән мөмкинлекләре, мораль яктан искергән технологияләрне куллану һәм нәтиҗәдә җитештерелгән продукциянең түбән конкурентлык сәләте.

Татарстан Республикасының икътисадый үсешенә дөнья базарларындагы төп чимал товарларына бәя конъюнктурасы, шулай ук сум курсы динамикасы сизелерлек йогынты ясый. Әлеге факторларның тотрыксызлыгы шартларында икътисадның реаль секторын тизләтелгән үстерү һәм сәнәгать җитештерүе структурасын оптимальләштерү зарурлыгы арта. Бер үк вакытта сумның югары волатильлеге һәм ягулык-энергетика ресурсларына бәяләрнең тотрыксызлыгы экспорт структурасын кардиналь үзгәртү һәм сәнәгатьне модернизацияләү, яңа предприятиеләр төзү, конкурентлы җитештерүне локализацияләү исәбенә импортны киметүне тәэмин итү бурычын катлауландыра.

Үзебезнең продукциянең конкуренциягә сәләтлелеген күтәрүгә комачаулый торган җитди проблема булып эшкәртү сәнәгате предприятиеләрендә инновацияләрне җитәрлек күләмдә кертү тора. Шул ук вакытта граждан билгеләнешендәге технологик продукция җитештерү өчен оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре мөһим резервка ия. Әмма дәүләт оборона заказы булган очракта, әлеге предприятиеләр гражданлык производстволарын үстерүгә мотивацияләнмәгән.

Сәнәгать үсешенең билгеләнгән проблемалары системалы характерга ия һәм программалы-максатлы ысул белән чишүне таләп итә.

Татарстан Республикасы эшкәртү тармаклары предприятиеләренең актуаль проблемаларын программалы-максатлы ысул белән чишү, икътисадый, социаль әһәмиятен, технологик критерийләрне исәпкә алып, түбәндәге өстенлекле юнәлешләр буенча башкарылырга мөмкин: сәнәгать предприятиеләренең төп фондларын яңартуга ярдәм итү, оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләренең потенциалын гражданлык билгеләнешендәге кирәкле продукция җитештерү өчен куллану, сәнәгать

инфраструктурасын һәм сәнәгать өлкәсендә эшчәнлекне хуплау инфраструктурасын булдыру һәм үстерүгә ярдәм итү.

## II. Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт сәясәте өстенлекләре һәм максатлары тасвирламасы

Татарстан Республикасы дәүләт программасының өстенлекләре Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективада үсешнең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маенда 309 номерлы Указына, Электрон сәнәгатьне үстерү стратегиясенә, Эшкәртү сәнәгатен үстерү стратегиясенә, 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешнең илкүләм максатларына ирешү буенча бердәм планга, Стратегия-2030 туры килә.

Татарстан Республикасы икътисады очраша торган актуаль проблемаларны бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең стратегик максатларына һәм бурычларына ирешү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт программасы күрсәткечләренең структурасы һәм системасы билгеләнде.

Татарстан Республикасы дәүләт программасының төп максаты – глобаль масштабта конкурентлыкка сәләтле, озак сроклы динамик үсеш потенциалына ия һәм Татарстан Республикасының стратегик өстенлекләрен тормышка ашыруны тәэмин итә торган сәнәгатьне үстерү өчен шартлар тудыру.

Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында дәүләт ярдәме күрсәтелгән предприятиеләр өчен 2027 елга планлаштырылган төп күрсәткечләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча төп капиталга инвестицияләр күләме (тупланган нәтиҗә белән) – 7,6 млрд.сум;

Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре (Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамый торган эшчәнлек төрләреннән тыш) буенча үзләре җитештереп, төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме (тупланган нәтиҗә белән) – 173,2https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=512750&dst=100711 млрд.сум;

Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы карамагындагы өлкәгә карамаган эшчәнлек төрләреннән тыш, Икътисадый эшчәнлек төрләре гомумроссия классификаторының «Эшкәртү производстволары» бүлегендәге икътисадый эшчәнлек төрләре буенча яңа кыйммәт булдыру (яңа төп фондларны гамәлгә кертү, модернизацияләү, реконструкцияләү) хисабына хисап елы өчен төп фондларның тулы исәпкә алу кыйммәтен арттыру (керү) (тупланган нәтиҗә белән) (федераль статистик күзәтү формасы буенча) – 5,7 млрд.сумга;

Татарстан Республикасы дәүләт программасын 2024 елдан 2027 елга кадәр финанслауның гомуми күләме 3,3 млрд.сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты хисабына – 0,9 млрд.сум, федераль бюджеттан җәлеп

ителәчәк чаралар хисабына – 1,0 млрд.сум, бюджеттан тыш чыганаклардан җәлеп ителәчәк чаралар хисабына – 1,4 млрд.сум.

## III. Стратегик өстенлекләр, илкүләм максатлар һәм Стратегия-2030 максатлары, Россия Федерациясе дәүләт программалары күрсәткечләре белән үзара бәйләнеш турында белешмәләр

Татарстан Республикасы дәүләт программасының максатлар системасы һәм бурычлары сәнәгатьнең тиешле тармакларының технологик һәм матди базасын яңарту һәм сәнәгатьне җитештерү чаралары белән тәэмин итү бурычларын гамәлгә ашыру өлешендә Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешнең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкурентлык сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 328 номерлы карары белән расланган «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкурентлык сәләтен арттыру» Россия Федерациясенең дәүләт программасы белән билгеләнгән Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларын, шулай ук Электрон сәнәгатьне үстерү стратегиясен, Эшкәртү сәнәгатен үстерү стратегиясен, 2030 елга кадәр һәм 2036 елга кадәр перспективада Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча юердәм планны, Стратегия-2030 исәпкә алып формалашкан.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә юнәлдереләчәк:

2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге перспективада төп капиталга инвестицияләр күләмен 2020 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда инвестиция климатын даими яхшырту исәбенә 2030 елга кадәр арттыру буенча «Тотрыклы һәм динамикалы икътисад» Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары;

Стратегия-2030ның түбәндәге максатлары:

«Татарстан Республикасының махсуслашу тармаклары төбәкара һәм глобаль базарларда конкурентлыкка сәләтле»;

«Татарстан Республикасында глобаль рәвештә көндәшлеккә сәләтле машина төзелеше кластеры нәтиҗәле эшли, ул югары өстәмә кыйммәт өлешен тудыра торган вертикаль интеграцияләнгән субкластерлардан тора: «Автомобиль төзелеше», «Авиация төзелеше», «Суднолар төзелеше» («Зирәк» машиналар» конвергент инновацион кластер булдыру белән). «Зирәк» җиһазлар» инновацион кластеры булдырылган һәм нәтиҗәле эшли. Металлургия, җиңел, агач эшкәртү, җиһаз һәм композит сәнәгатендә кластерлы үсеше бара»;

сәнәгатьнең тиешле тармакларының технологик һәм матди базасын яңарту һәм сәнәгатьне җитештерү чаралары белән тәэмин итү бурычларын гамәлгә ашыру өлешендә «Сәнәгатьне үстерү һәм аның конкурентлык сәләтен арттыру» Россия Федерациясе дәүләт программасы максатлары;

«Җитештерү чаралары» юнәлеше өлешендә Электрон сәнәгатьне үстерү стратегиясенең максатлары: электрон продукцияне эшләүнең, җитештерүнең һәм аларга сервис хезмәте күрсәтүнең төп процессларының таләп ителә торган матди-техник базасын тәэмин итәргә.

## IV. Дәүләт идарәсе бурычлары, аларны сәнәгатьнең эшкәртү тармакларында һәм дәүләт идарәсе даирәсендә нәтиҗәле хәл итү ысуллары

Татарстан Республикасы дәүләт программасы максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителә:

сәнәгатьнең эшкәртү тармаклары предприятиеләре тарафыннан җиһазларның лизингын стимуллаштыру;

сәнәгатьнең эшкәртү тармаклары предприятиеләрен яңа җиһазлар сатып алуга стимуллаштыру;

Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Сәнәгать предприятиеләренә җиһазларны Россия лизинг оешмалары белән лизинг шартнамәсе (шартнамәләре) төзегәндә беренче кертемне (аванс) түләүгә чыгымнар өлешен каплау» чарасы буенча 2023 елда төзелгән субсидияләр бирү турындагы шартнамәләрнең үтәлешен тикшереп тору;

Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Яңа җиһазлар сатып алуга бәйле сәнәгать предприятиеләре чыгымнарының бер өлешен каплау» чарасы буенча 2023 елда төзелгән субсидияләр бирү турындагы шартнамәләрнең үтәлешен тикшереп тору;

Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Сәнәгать предприятиеләренә җиһазларны Россия лизинг оешмалары белән лизинг шартнамәсе (шартнамәләре) төзегәндә беренче кертемне (аванс) түләүгә чыгымнар өлешен каплау» чарасы буенча 2024 елда төзелгән субсидияләр бирү турындагы шартнамәләрнең үтәлешен тикшереп тору;

Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Яңа җиһазлар сатып алуга бәйле сәнәгать предприятиеләре чыгымнарының бер өлешен каплау» чарасы буенча 2024 елда төзелгән субсидияләр бирү турындагы шартнамәләрнең үтәлешен тикшереп тору;

Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән субсидия бирү турында;

гражданлык билгеләнешендәге продукция җитештерү өчен оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре потенциалыннан файдалануны стимуллаштыру;

электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзүгә, үстерүгә һәм (яисә) модернизацияләүгә идарәче компанияләрнең документаль расланган чыгымнары өлешен финанс белән тәэмин итү яисә каплау;

пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр буенча фәнни-җитештерү үзәкләре челтәрен булдыруга.

Куелган бурычларны хәл итүне түбәндәге чараларны үткәрү юлы белән гамәлгә ашыру максатка ярашлы була:

сәнәгать предприятиеләренә Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә беренче кертемне (авансны) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау;

сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһаз сатып алуга бәйле чыгымнарының бер өлешен каплау;

Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Сәнәгать предприятиеләренә җиһазларны Россия лизинг оешмалары белән лизинг шартнамәсе (шартнамәләре) төзегәндә беренче кертемне (аванс) түләүгә чыгымнар өлешен каплау» чарасы буенча 2023 елда төзелгән шартнамәләр буенча сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү;

«Яңа җиһазлар сатып алу белән бәйле сәнәгать предприятиеләренең чыгымнарының бер өлешен каплау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чарасы буенча 2023 елда төзелгән субсидия бирү турында килешүләр буенча сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Сәнәгать предприятиеләренә җиһазларны Россия лизинг оешмалары белән лизинг шартнамәсе (шартнамәләре) төзегәндә беренче кертемне (аванс) түләүгә чыгымнар өлешен каплау» чарасы буенча 2024 елда төзелгән шартнамәләр буенча сәнәгать өлкәсендәге эшчәнлек субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү;

«Яңа җиһазлар сатып алу белән бәйле сәнәгать предприятиеләренең чыгымнарының бер өлешен каплау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы чарасы буенча 2024 елда төзелгән субсидия бирү турында килешүләр буенча сәнәгать өлкәсендә эшчәнлек субъектларының йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итү;

Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционерлык җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән субсидия бирү турында;

Оборона-сәнәгать комплексы оешмаларына гражданлык билгеләнешендәге продукция чыгаруга бәйле чыгымнарның бер өлешенә субсидияләр бирү;

идарәче компанияләрнең электрон сәнәгать өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яисә) модернизацияләү өчен документаль расланган чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итүгә яисә каплауга түләү гамәлгә ашырылды;

Татарстан Республикасы территориясендә пилотсыз авиация системалары технологияләрен үстерү өлкәсендә сынаулар һәм компетенцияләр фәнни-җитештерү үзәген җиһазлар, шулай ук аларның компонентлары һәм комплектлаучылары белән тәэмин итү.

Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен, Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан юридик затларга субсидияләр бирү һәм бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру кагыйдәләрен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында капитал салуларны гамәлгә ашыру турында карарларны раслый торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлеге

| Т/с | Документ тибы | Документ төре | Документ исеме | Реквизитлары | Эшләүче | Документ текстына гиперссылка |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| «Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы | | | | | | |
| 1. | Төбәк норматив акты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | 2025 елда Россия лизинг оешмалары белән җиһаз лизингы шартнамәсен (шартнамәләрен) төзегәндә сәнәгать предприятиеләренә беренче кертемне (аванс) түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында | 27.09.2023 № 1187 | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1260426 |
| 2. | Төбәк норматив акты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | 2025 елда сәнәгать предприятиеләренең яңа җиһазлар сатып алуга бәйле чыгымнары өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында | 27.09.2023 № 1188 | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1260546 |
| 3. | Төбәк норматив акты | Татарстан Республикасы | Татарстан Республикасында электрон сәнәгать | 19.12.2023 № 1639 | Татарстан Республикасы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1330451 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Министрлар Кабинеты карары | өлкәсендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү проектларын сайлап алуны үткәрү тәртибен һәм Электрон сәнәгать өлкә--сендә сәнәгать технопарклары инфраструктурасы объектларын төзү, үстерү һәм (яки) модернизацияләү өчен сәнәгать технопаркларындагы идарәче компанияләренең документаль расланган чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү яисә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында | | Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | |
| 4. | Төбәк норматив акты | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары | 2025 елда Зеленодольск моношәһәрендә «СПГ эре тоннажлы компрессор агрегатлары җитештерү комплексы» инвестиция проектын «Казан компрессор машина төзелеше заводы» акционер җәмгыяте тарафыннан гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү | 16.10.2025 № 832 | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы | https://pravo.tatarstan.ru/npa_kabmin/post/?npa_id=1692564 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | максатларында сәнәгатьне үстерү фонды вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасына эшчәнлекне финанс белән тәэмин итүгә (докапитализациягә) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында | | | |